КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 март г.Казань № 140

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 ел, 15 июнь, 468 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 декабрь, 1087 нче; 2011 ел, 29 июнь, 526 нчы; 2011 ел, 29 июль, 609 нчы; 2011 ел, 7 июль, 747 нче; 2012 ел, 27 апрель, 330 нчы; 2012 ел, 30 июнь, 567 нче; 2012 ел, 30 июль, 645 нче; 2012 ел, 27 октябрь, 908 нче; 2013 ел, 19 март, 186 нчы; 2013 ел, 29 апрель, 296 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1111 нче; 2014 ел, 20 май, 332 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1039 нчы; 2015 ел, 10 март, 143 нче; 2016 ел, 26 февраль, 118 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 996 нчы; 2017 ел, 18 май, 291 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 278 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1156 нчы; 2019 ел, 29 гыйнвар, 52 нче; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2019 ел, 13 июнь, 492 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 815 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 866 нчы; 2019 ел, 30 сентябрь, 883 нче; 2020 ел, 24 февраль, 132 нче; 2020 ел, 17 апрель, 300 нче; 2020 ел, 27 август, 747 нче; 2021 ел, 28 июнь, 509 нчы; 2021 ел, 25 август, 781 нче; 2021 ел, 23 декабрь, 1269 нчы; 2022 ел, 7 июнь, 534 нче; 2022 ел, 7 июнь, 534 нче; 2022 ел, 9 сентябрь, 970 нче; 2023 ел, 3 апрель, 396 нчы, 2023 ел, 27 июль, 897 нче, 2023 ел, 30 ноябрь, 1538 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы

276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

4.1 пунктның 4.1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәяләр турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 нче карары белән расланган Электр энергетикасында җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәяләр билгеләү нигезләренең 101 пунктында каралган очракларда, мондый бәяләрнең (тарифларның) чик (минималь һәм (яисә) максималь) дәрәҗәләре тарифларын җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы билгеләгән кысаларында милек хокукында яисә башка законлы нигездә территориаль челтәр оешмаларыныкы булган, шул исәптән Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә эшчәнлек алып баручы электр челтәрләре буенча электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) билгели.»;

4.6 пунктта:

4.6.8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.8. Түбәндәге хезмәтләр күрсәткән өчен җыемнар күләмен билгели:

машинага дәүләт теркәү билгеләрен һәм паспортларын, тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыкларын, үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына вакытлы таныклыкларны, машина (машиналар) залогын һәм башка махсус продукцияне теркәү турындагы таныклыкларны бирү һәм алмаштыру;

үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар алу;

үзйөрешле машиналарга һәм техниканың башка төрләренә техник тикшерүлщр үткәрү;

«сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмауга карата күзәтү астындагы машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу.»;

4.6.12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.12. Законнарда каралган очракларда транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә, шулай ук эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләренә бәяләр (тарифлар, җыемнар) һәм (яисә) иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) бәяләр (тарифлар, җыемнар) билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин